**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

2021 елның 19 ноябре № 60

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча, аның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү һәм әлеге мәсьәләне норматив-хокукый җайга салу булган вәкаләтләрен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендагы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 һәм 15 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының "Бишнә авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Бишнә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча, аның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү һәм әлеге мәсьәләне норматив-хокукый җайга салу булган вәкаләтләрен тапшырырга.

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча, аның предметы булып, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү һәм әлеге мәсьәләне норматив-хокукый җайга салу булган вәкаләтләрне тапшыру турында килешүләр төзергә тәкъдим итәргә.

3. Вәкаләтләрнең бер өлешен тормышка ашыруны Яшел Үзән муниципаль районының Бишнә авыл җирлеге бюджетыннан ел саен Яшел Үзән муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына башкаралар.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында урнаштыру Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Яшел Үзән муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Бишнә авылы, Үзәк урамы, 5

(Советның административ бинасы), Бишнә авылы, Школьная урамы, 10 (Бишнә авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, социаль-икътисадый үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре, муниципаль милек һәм эшкуарлыкны үстерү комиссиясенә йөкләргә.

**Бишнә авыл**
**җирлеге башлыгы, Совет рәисе** **И.М.Фатхуллин**